АССОЦИАЦИЯ
«СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНЫХ ОБРАЗОВАНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ СОВЕТЫ»
АССОЦИАЦИЯСЕ

**РЕШЕНИЕ ПРЕЗИДИУМА** **ПРЕЗИДИУМ КАРАРЫ**

от 10.06.2021 № ПР-17-2

г. Казань

**2021 елның 12 мартында «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе президиумының «Җирлекләрнең территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелеше зоналаштыру документларын әзерләү һәм Татарстан Республикасы торак пунктлары чикләре турындагы мәгълүматларны күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрына кертү буенча эшләрнең барышы» турындагы карарын үтәү турында**

Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары вазифаларын башкаручы Т.Ф. Хөснетдиновның, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары В.Н. Кудряшевның мәгълүматларын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе Президиумы (алга таба – Совет), **карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары вазифаларын башкаручы Т.Ф.Хөснетдинов һәм Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары В. Н. Кудряшев мәгълүматларын игътибарга алырга.

2. Татарстан җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына муниципаль берәмлекләр башлыкларына территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру документларын закон таләпләренә туры китерү буенча эш барышын карау турында муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының эш төркемнәре утырышы нәтиҗәләре буенча беркетмә җибәрергә тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына шәхси контрольгә алырга тәкъдим итәргә:

- территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру

документларын закон таләпләренә туры китерү буенча эш барышын карау турында муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының эш төркемнәре утырышы нәтиҗәләре буенча беркетмәнең үтәлешен тәэмин итү;

- территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру документларын әзерләү буенча комплексы чаралар үткәргәндә, әлеге органнар тарафыннан билгеләнгән кирәкле мәгълүмат бирү вакытларын үтәү;

- территориаль планлаштыру документларын әзерләү буенча чараларны финанслауга инвесторларны җәлеп итү буенча кирәкле эш алып бару.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Советның башкарма сәркатибе А.Г. Барышевка йөкләнә.

**Рәис** **Э.С. Гобәйдуллин**